Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№30 (123)

23 октябрь 2014 ел



Шагыйрь кешенең күңеле тынгысыз дулкын кебек: ул гел җил сорый, аның, җимереп булмаслык горур ярларга бәрелеп, шунда үз бизәкләрен калдырасы килә. Кешеләргә ул бизәкләрне кем ясаганы мөһим түгел, ләкин алар, ул бизәкләрне күреп, үзләренә рухи азык, күңел тынычлыгы алсыннар иде. Табигатьтә су һәм җил булганда, шигърият тә яшәр.

Булат Ибраһим

## Тәүге балкыш!

● Фән дөньясында

20-24 октябрь көннәрендә КФУда профессор М.Т.Нужинның 100 еллыгына багышланган «Кире кырый мәсьәләләре һәм аларның кушымталары» дигән Бөтенроссия фәнни конференциясе үтә.

# Һәр өлкәдә мактауга лаек

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты



Михаил Тихонович Нужин – 1954-1979 елларда Казан университеты ректоры, профессор, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе, Казан фәнни кире кырый мәсьәләләре мәктәбенә нигез салучыларның берсе. 21 октябрь көнне университетның Актлар залында танылган галимне аның укучылары, чордашлары искә алды. Чарада ректор И.Гафуров та катнашты. «60-70 елларда М.Т.Нужин оештырып формаларштырган үсеш юнәлешләрен без, үз чиратыбызда, 2010 елда университет федераль автоном белем бирү учреждениесе статусын алганнан соң дәвам иттек», – диде ректор.

Пленар утырышта галимнең тормыш юлы, холкы, фәнни һәм педагогик эшчәнлеге, университет үсешенә керткән идеяләре, эшләгән эшләре турында сөйләнде. 1999-2001 елларда КДУ ректоры булган Ю.Г.Коноплев талантлы математик һәм механикның биграк тә кешелеклелек сыйфатларын искә алды. Рәсәй академиясе академигы А.И.Коновалов исә аның тәрбия эшчәнлеген яктыртты, укытучыларда һәм студентларда университетка карата горурлык хисен булдырырга тырышуын искәртеп узды. Академик, шулай ук, аның ярты гомерен Казан университетына багышлавын ассызыклады. Фәнни эшчәнлеге турында профессор М.Илгамов сөйләде.

М.Т.Нужин ректорлык иткән чорда университет көчле темплар белән үсә: КДУда бионика, биофизика, биохимия, ярымүткәргечләр физикасы һәм химиясе кебек яңа юнәлешләр барлыкка килә. Университет диварларында исәпләү үзәге оеша. Яңа укыту-лаборатор корпуслар төзү һәм җиһазландыру буенча актив эш алып барыла. Студентлар өчен тулай тораклар төзелә.

Болардан кала, М.Т.Нужин – аналитик функцияләр һәм аларның кушымталары өчен кире кырый мәсьәләләренең математик теориясен барлыкка китерүчеләрнең берсе. Математика һәм механика өлкәсендәге казанышларының, хезмәтләренең һәркайсы мактауга лаек булган киңкырлы шәхес ул.

Өч көн дәвамында конференциядә катнашучылар кире кырый мәсьәләләренең математик теориясе, механика өлкәсенә караган мәсьәләләр, проблемалар турында фикер алышты, тәҗрибә уртаклашты.

● Чара

# Җир астында ниләр бар?

**Дания ФАТЫЙХОВА**

Бу сорау шулай ук Россиянең 72 төбәге һәм 22 чит илдән 950ләп җир асты серләрен өйрәнүче галимне дә борчый. Аларның Казанда үткәрелә торган IV (XX) Бөтенроссия археология съездына җыелуларының сәбәбе дә нәкъ шунда.



*Казан – археологик тарихи-мәдәни һәм борынгы үзәкләрнең берсе. Һәм шәһәребездә шундый киң масштаблы чараның уздырылуы Татарстан башкаласының авторитеты турында сөйли. Әлбәттә, мондый чарадан Казан федераль университеты да читтә кала алмый һәм корылтайны уздыру урыны итеп нәкъ менә КФУның сайлануы дәрәҗә күрсәткече булып тора.*

Корылтай 20 октябрьдә башланып китте. Бөтенроссия археологиясъезды Россиянең яңа тарихында дүртенче тапкыр уздырылса, империя чорыннан алып санасак, бу аның инде егерменче тапкыр оештырылуы. Археология яссылыгында Татарстан башкаласы гел игътибар үзәгендә була. 1877 елда шәһәребездә Россия империясенең IV Бөтенроссия археология съезды үткәрелә. Кызганыч, совет чорында археологлар җыены оештырылмый. Онытылган корылтай бары 90 елларда яңә үткәрелә башлый. Һәм 137 елдан соң, тарихчы галимнәр яңадан Казанда җыелырга уйлый.

Өч елга бер уздырыла торган корылтай быел катнашучылар саны ягыннан күп булуы белән аерылып тора. Моңарчыга кадәр әле бер шәһәр дә моның кадәр белгечне туплый алмаган. Хәер, бу өлкәдә Казан башка шәһәрләрдән бик нык аерыла. Республикада археологиянең ни дәрәҗәдә алга киткәнен 7 музей-тыюлык кына да исбатлап тора.

Корылтайның ачылыш тантанасы һәм пленар утырышында бик дәрәҗәле һәм хөрмәтле кунаклар катнашты. Алар арасында КФУ ректоры И.Гафуров та бар иде. Аның сүзләренчә, Казан университеты Россия археология фәненә үзеннән зур өлеш керткән. И.Гафуров университетыбызда өйрәтелә торган археология фәненең тарихы турында сөйләде, Загоскин, Катанов, Бодуэн-де-Куртенэ кебек галимнәрне искә алды һәм КФУ археолог-галимнәренең бүгенге көндә дә элек эшләүчеләрнең тикшерү эшләрен актив рәвештә дәвам итүләрен ассызыклады. «Шулай ук университетыбызда Археометрия өстенлеге үзәге ачыла. Безнең мәйданда яңа ачык лабораторияләр булдырыла. Без хезмәттәшлеккә әзер», – дип, уртак эшчәнлеккә өндәде университет җитәкчесе.

Әлбәттә, съездда университетыбыз галимнәре дә катнаша. Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты профессоры А.Борһанов берничә секция утырышында катнаша: «Әлеге корылтай, беренче чиратта, бөтен археологларны бергә туплый, берләштерә. Биредә без башкарган эшләргә нәтиҗә ясыйбыз, планнар корабыз, яңа мәсьәләләрне билгелибез. Әлбәттә, фикер алыша торган проблемаларның спектры бик киң. Мисал өчен, кара археология, археологик мәдәният һ.б. Коллегаларым бик кызыклы һәм файдалы



чыгышлар ясый», – дип ассызыклый ул.

IV Бөтенроссия археология корылтае 25 октябрьгә кадәр дәвам итәчәк. 5 көн дәвамында, Татарстан тәҗрибәсеннән тыш, археологлар Евразия киңлекләрен өйрәнү буенча фикер алышачак. Шулай ук биредә археология һәм тарих фәненең актуаль мәсьәләләре, Россия халкының археологик мирасын саклау мәсьәләләре, борынгы археологик һәйкәлләрне реставрацияләү, музейләр төзү, мәгариф системасында археологиянең роле һ.б. сорауларга җавап эзләячәкләр.

● Халыкара мөнәсәбәтләр

# Татар тарихын Япониядә дә өйрәнәләр

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Шушы көннәрдә КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү институтында «1914-1918нче еллардагы бөек сугыш: Россия, Аурупа һәм Ислам дөньясы» дип аталган Халыкара фәнни форум булып узды.



Чара кысаларында «Дәүләт Думасы һәм Беренче Бөтендөнья сугышы», «Мөселман дөньясы һәм Беренче Бөтендөнья сугышы» фәнни конференцияләре үткәрелде. Форумның төп фәнни юнәлешләре парламентаризм тарихы һәм дөнья тарихындагы тамырдан борылыш чорларында ислам факторының роле белән бәйле булды. Бүген дә актуаль булган бу мәсьәләләр уңаеннан фикер алышырга төрле илләрдән галимнәр җыелды. Чыгыш ясаучылар арасында тарихчы Норихиро Наганава да бар иде.

Бүген Норихиро Наганава Япониянең Саппоро шәһәрендәге Хоккайдо университеты каршындагы Славян һәм Евразия халыкларын өйрәнү үзәгендә доцент булып эшли. Форумда катнашучыларга ул Беренче Бөтендөнья сугышы елларында Идел-Урал төбәге мөселманнарының хәйриячелеге, «җәмгыяте хәйрия»ләрнең ул чордагы уку-укытуны ни рәвешле оештыруы турында тәфсилләп сөйләде.

Норихиро әфәнде Токио университетының Көнчыгыш телләр бүлеген тәмамлаганнан соң, 2001-2003 елларда Казан университетына стажировка узарга килә. Бу чорда ул докторлык диссертациясенә материал туплау белән мәшгуль була. Нәкъ менә шушы вакытта Норихиро Наганава татар филологиясе факультеты укытучылары белән дуслашып китә, татар телен өйрәнә. Бу уңайдан ул Флера Сафиуллина исемен аерата бер җылылык белән искә ала. Татар телен белү аңа тикшеренүләр үткәргәндә дә ярдәм итә икән. Моңа өстәп галим рус, инглиз, төрек, гарәп, алман һәм француз телләрен дә үзләштергән.

Хәзерге көндә Норихиро Наганава Хоккайдо университеты каршындагы Славян һәм Евразия халыкларын өйрәнү үзәгендә XIX-XX гасырда дин әһелләренең татар һәм башкорт җәмгыятьләрендә тоткан урынын өйрәнә. Бер үк вакытта галим күренекле совет дипломаты һәм революционеры Кәрим Хәкимовның эшчәнлеге турында да мәгълүмат җыя. Бу тарихи шәхес Совет Русиясенең гарәп илләрендәге беренче вәкаләтле вәкиле булган, Советлар Союзы белән гарәп-фарсы дәүләтләре арасында җылы мөнәсәбәт урнаштыруда әһәмиятле роль уйнаган. Баксаң, ул башкортларның милли каһарманына әверелгән. Ә татарларда аны сирәкләр генә хәтерли. Замандашыбыз – журналист, җәмәгать эшлеклесе Римзил Вәлиев исә Кәрим Хәкимов нәселенең бер дәвамчысы икән. Галим бу моментны да билгеләп узды.

Норихиро әфәнде, Кәрим Хәкимовка бәйле документларны табу һәм өйрәнү максатыннан, Казан, Уфа, Мәскәү һәм Лондон архивларында эзләнгән. Бу эшен ул бүген дә дәвам итә. Ә татар тарихында бөтенләй өйрәнелмәгән исемнәр һәм вакыйгалар күп әле.

Хәтер-хатирә

# Ватык транспарант, милиция һәм Әлфәт абый...

**Айсылу МӨБӘРӘКШИНА**, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Ни гаҗәп, һәр кеше дә студент чакларын иң матур еллары буларак искә ала. Без, бүгенге студентлар, ни өчендер, әлеге сүзләрнең асылына төшенеп җитә алмыйбыз. Татар әдәбияты һәм аны укыту методикасы кафедрасы доценты, октябрь аенда үзенең күркәм юбилеен билгеләп узган Әлфәт абый Закирҗанов яшьлек хатирәләрен яңартып, студент елларын искә алды.



«Без дә кайчандыр студентлар идек. Безнең студент тормышы шулай ук сезнеке кебек кызыклы, шау-шулы иде һәм шул ук вакытта төрле борчулы хәлләр белән кушылып барды. Совет хөкүмәте вакытында, яз һәм көз көннәрендә, демонстрациягә чыга идек. Институт тирәсенә җыелабыз, безне аннан алып китәләр. М.Горький урамыннан өскә менеп, хәзерге Корстон каршына, К.Маркс урамына чыгабыз һәм шуннан Ирек мәйданы аша үтәбез. Шушы демонстрация вакытында кулларга күтәреп барырга төрле әйберләр бирәләр. Кемгәдер флаг, кемгәдер партия җитәкчеләренең фоторәсемнәре эләгә, ә безгә, бервакыт, икенчеме-өченчеме курста укыганда, Бөек Октябрь Социалистик революциясе уңаеннан демонстрациягә чыгар алдыннан, икеме-өчме егеткә өч тәгәрмәчле транспарант биределәр. Ялгышмасам, анда Ленин портреты төшерелгән кебек иде. Шулай туры килде ки, ул вакыттагы спорт факультеты бинасы яныннан К.Маркс урамына борылганда, ул ватылды һәм без аны нишләтергә белмәдек. Шунда гына төзәтергә мөмкинлек юк, ә күтәреп барасы килми. Һәм, гадәттәгечә, яшьлек-җүләрлекме, әллә нәрсә тирәннән уйламадык, без әлеге транспарантны үзебез тора торган тулай торакка алып кайтып киттек. Ул көнне транспарант белән йөрүчеләр күп иде. Ләкин иң кызыгы шунда ки, аннан соң без ике-өч көн ял иттек. Ә транспарантны кул куеп алдык, без аның өчен җаваплы. Һәм без «Пионерская» тукталышыннан алып университетка кадәр әлеге транспарантны күтәреп һәм этеп килергә мәҗбүр булдык. Күз алдына китерегез: урамнан машиналар, трамвайлар үтә, кешеләр йөри, һәм без, ике-өч егет, ярты шәһәр буйлап әлеге транспарантны күтәреп киләбез. Андый вакытта инде ни еларга, ни көләргә дә белмисең».

* * *

«Без укыган чорларда студентларны милициягә ярдәмгә чыгаралар иде. Берсе БКД (Боевая комсомольская дружина) дип атала иде, ә икенчесе – халык дружинасы (ДНД – «Добровольная народная дружина»). Беренчесенә бик актив комсомоллар, үзләре милиция белән якыннан эш иткән кешеләр керә иде, икенчесе студентлар һәм төрле завод-фабрика эшчеләреннән тора. Безнең факультетка бер атна бирелә, шул вакыт эчендә без хәзерге тимер юл вокзалы тирәсендәге микрорайонда кичке алтыдан тугызга кадәр дежур торабыз, безгә бер милиционер беркетәләр иде. Нигездә, без һәр чыккан саен берме-икеме исерек кешене тотып кайта идек. Аларны вокзалдан тотып алып килгәч, участокта протокол язалар һәм шунда кунарга да калдыралар иде. Шулай бервакыт бер исерекне алып кайттык. Протоколлар тутырдык, сөйләштек, аңлаттык, студент буларак вәгазь дә укыдык әле. Соңыннан, эш беткәч кенә, бер иптәшебез әлеге кешедә туганнан туган абыйсын танып алды. Абыйсы Буадан килгән, поездга соңга калган, көне буе йөреп арыган, ял итәргә генә утырган булган һәм йокыга киткән, нәтиҗәдә аны вокзалдан куып чыгарганнар. Соңыннан ул кешене җибәрделәр. Без аны үзебез белән тулай торакка алып кайтып, комендантан рөхсәт сорап, кундырып та чыгардык. Менә шундый хәлләр дә булгалады».

Очрашу

Бу юлы филология фәннәре кандидаты Рәсимә Муллаян кызы Галиеваның «Журналист тикшерүе» курсында тыңлаганнар үтә дә кызыклы булды. Чөнки без, 4 нче курс студентлары, укытучы белән түгел, ә үзенчәлекле шәхес белән әңгәмә кордык. Үзенчәлеге аның сүзендә, Сиражи сүзендә.

# Бизнесмен журналисттан мастер-класс

**Диләрә БАТРШИНА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Аның өчен ябык тема, чишелеше булмаган проблема, кагылгысыз шәхес һәм чикләүләр юк. Тәвәккәл һәм курыкмас – журналистика кырында аны сыйфатлаучы ике сүздер бу. Үткен язма теле, максатчан булуы белән ул бүгенге исемен, репутациясен булдырган. Нәкъүзе, һәркемгә таныш булган Искәндәр Сиражи, безгә мастер-класс үткәрде.

Бизнес белән шөгыльләнүче кеше пунктуаль, аз сүзле, эшлекле була. Кат-кат үзенең шул сфера вәкиленә әйләнүен искәртсә дә, әллә чын журналист булганга, Искәндәр Сиражи безнең белән бик иркен аралашты. Артык күп сорау да кирәк булмады, ул үзенең биографиясе, журналист эшчәнлеге, «Сиражи сүзе» исеме белән чыга торган газетасы турында бер сулышта сөйләде. Без бары тик тыңлап, мәгълүматны сеңдереп, еш кына аның кызыклы истәлекләреннән көлешеп утырдык. Җанлы сөйләшү озакка сузылды, әмма талчыктырмады.

Искәндәр Сиражи безнең янга, иң беренче чиратта, журналист тикшерүен дөрес һәм төгәл алып баручы буларак килде. Тикшерүне ничек үтемле һәм нәтиҗәле итеп башкарырга, соңыннан тупланган мәгълүматны язмада ничек кулланырга – барысына да төшендерде кебек. Моның белән беррәттән, психологик тест нәтиҗәсендә аның чын журналист булуын да ачыкладык (әлеге тестны алдагы курс студентлары да үтәсе булганга, сер булып калсын). Әмма соңыннан аның «журналистикада акча эшләп булмый», дигән сүзе миндә бераз шик уятты. Чын журналист алай уйларга тиешме икән?

Әлбәттә, Искәндәр Сиражи бик кызыклы һәм үзенчәлекле шәхес. Мәкаль белән әйткәндә, утны-суны кичкән кеше. Үзенең күпьеллык журналистлык эшчәнлеге барышында ул еш кына конфликтка керә, каршылыкка очрый. Гаеплене урынына утыртып, кимчелекләрне күрсәтеп, тәнкыйди төстә язмалар иҗат итеп, ул үзенә дошманнар да, дуслар да җыеп өлгергән. Шуңа күрә, үзе сөйләгәнчә, аның белән күңелсез хәлләр дә булгалый: тормышына янау, машинасын шартлату, эшендә аяк чалу һәм башкалар. Хәтта гаиләсе дә һәрчак сакчылар күзәтүендә йөри икән. Боларның барысын да тыңлап утыру нәтиҗәсендә, миндә бер сорау туды. Ләкин очрашу күтәренке нотада баргангамы, әллә үземчә артык фәлсәфәгә бирелү булыр дип бәяләгәнгәме, мин аны басып әйтә алмадым. Форсаттан файдаланып, язмамны шул риторик сорау белән тәмамлыйсым килә: Искәндәр абый, ә сез мондый тормышыгыздан канәгатьме?!



Безнекеләр



# «Татар team» – чемпион!

«Иҗат – гүзәл гамь ул, иң югары дәрәҗәдәге изге тынгысызлык», дигән Хәсән Туфан. Сүзем нәкъ тә тынгысызлыкта тынгысызланып яши торган «Татар team» КВН командасы турында.

**Эльвина НӘҖИПОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Әлеге команда – Г.Тукай ис. татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенең генә түгел, ә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының йөзек кашы. Әлеге команда, үткән уку елында гына оешуына карамастан, бүгенге көндә зур уңышларга ирешә. Татар КВН Лигасында – 2нче урын, «Сәләт» КВН Лигасы фестивалендә җиңүче һәм тагын да сөендергәне – 15 октябрь көнне «Ак Барс» яшьләр үзәгендә үткән әлеге Лиганың чемпионы!

Лигада финалга узу бәхетенә ирешкән 4 команда үзара көч сынашты. Чара дәвамында «Новые люди» («Сәләт»), «Сборная Счастливых людей» («Сәләт»), «Венеция» (Казан шәһәренең 37 гимназиясе) һәм безнең «Татар team» уенчылары сәхнәне «кыздырды». Командалар үз көчләрен 3 төрле бәйгедә: сәламләү, разминка һәм фристайлда сынап карады. Катнашучыларның уенга җитди әзерләнгәне беренче чыгышлардан ук сизелде. Эшнең иң авыры, әлбәттә, жюри әгъзаларына төште: алардан гадел хөкем һәм дөрес бәя таләп ителде. Бу юлы да тамашачы командалар арасындагы бердәмлекне, бер-берсенә булышу, ярдәм итү теләген һәм дуслык хисенең көчле булуын уен дәвамында күзәтеп, сөенеп утыргандыр.

Нәтиҗәләргә килгәндә, 3нче урынга «Сборная Счастливых людей» командасы лаек дип табылды. 2нче урынны 37 гимназия укучылары яулады. Ә чемпион итеп «Татар team» командасы танылды. Аларга Студентлар Лигасында катнашу мөмкинлеге бирелде. Лига 28 октябрь көнне Алабуга шәһәрендә үтәчәк. Алар, уенга кадәр төрле кызыклы мастер-класслар үтеп, КВН мәктәбендә булачаклар.

Без институт, бүлекнең барлык студентлары, укытучылары исеменнән «Tatar team» командасына уңышлар һәм яңа җиңүләр теләп калабыз!

**Әдәби сәйләннәр**




# Тәүге балкыш!

Булат Ибраһим! Бу исем сезгә яхшы таныш! Бүген Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты аспиранты Булат үзенең иҗатын яратучыларга яхшы хәбәр җиткерә. Күптән түгел аның «Балык теле» дип исемләнгән тәүге китабы дөнья күрде. Без иҗатташ дустыбызны бу шатлыклы вакыйга белән чын күңелдән котлыйбыз! Алга таба да уңышлар теләп калабыз. Түмле әйбер күп булмый дигәндәй, сезнең игътибарга яшь шагыйрьнең берничә шигырен тәкъдим итәбез.

## Төнге күк

*Тулпар ат тыпырчынганнан*
*Кутәрелгән ак томан,*
*Тояклардан калган эзләр*
*Алтыннан. Кузне йомам.*

*Җанга шундый якын бу күк,*
*Җаннан шундый ерак ул.*
*Батырлардай нык бәгырьле,*
*Хисчәннәрдәй елак ул.*

*Миңә бүген елый ул күк*
*Яшьләр белән түгел лә.*
*Чем-кара зур күзләреннән*
*Чиксез йолдыз түгелә.*

*Әй, төнге күк, күл әле бер,*
*Күл әле, миңа кар ат.*
*Караңгы нурларыңа да*
*Күңел һич туймый карап.*

## Туган тел

*- Шушымы ул? Әй, син?*
*Сиңа әйтәм!*
*Шушымы ул, чүәләгән,*
*хәер сорап тора?*
*Шушымы ул, ис(е)рен бетен,*
*Пычрап, елап тора.*
*- Шушы,*
*Ә син – шуның улы,*
*Ә ул әнә кызы аның.*
*Качалмыйсыз,*
*Сездә шуның каны, даны.*
*- Әй, син,*
*Ә без хәзер нишләтик соң аны?..*
*Ул ютәлли,*
*Авызыннан төтен белән*
*Язмыш караңгысы сибелә,*
*Күзләреннән бераз гына*
*нур бөркелә.*
*Ул кыйналган.*
*Ятим бит ул кыйналмаска.*
*Башин түбән игән,*
*Язмыш аны сөйри аска,*
*Аска, аска – чыгалмаска...*
*Сеңел, әйдә тот кулыннан,*
*Өчәү булсак, җиңелрәк булыр*
*югалмаска.*

***

*Тулай торак.*
*Аннан ерак түгел*
*Үзбәк ашханәсе тирәсендә*
*Сине көтеп йөрим.*
*Тулай торак.*
*«Гадел Кутуй» тукталышы.*
*Тапшырасы хатлар*
*Тапшырылды инде,*
*Әйтер сүзләр калды уйда*
*Буталышып.*
*Тулай торак.*
*Аның тирәсендә*
*Тупыл коя яфрак,*
*Тукталышка карап,*
*Озатып кала кызыл автобусны...*
*Ә син хәзер ерак,*
*Мин дә синнән ерак.*
*Тулай торак тәрәзәсе*
*Карап тора елап*

## Балык теле

*Яңгыр ява,*
*Урам тулы куллар,*
*Урам тулы күзләр*
*Һәм телсезләр тәгәрәшә.*
*Алар белән мин яңәшә,*
*Ләкин түгел бергә.*
*Мин гомергә*
*Алар белән булмам,*
*Ярдәм итсә Ходам.*
*Яңгыр ява...*
*Балык теле укытучысы*
*Кайтып килә,*
*Көлә-көлә, күлне таптап,*
*Балыкларын саный*
*Акрын гына атлап.*
*Ул безнеке түгел,*
*Әллә каян укып кайткан,*
*Сатлык күңел,*
*Балык телен алып кайткан*
*Сатып ана телен.*
*Балык теле,*
*Шундый җиңел тел ул,*
*Хәрефләре дә юк, язуы да,*
*Тарихын да аның беркем белми,*
*Кирәк түгел артык казыну да,*
*Кирәк түгел китап язуы да.*
*Кирәк түгел, берни кирәк түгел...*
*Ул телне өйрәнсәң,*
*Йокың татлы,*
*Тыныч шаулы күңел.*
*Чиләкләрдән чиктән ашып түгел,*
*Юлларыңа бәхет тулса,*
*Берни кирәк түгел...*
*Яңгыр ява,*
*Ә кулларда балык туе бара,*
*Халык туе кадәр...*
*Балык теле бездә,*
*Атасыннан баласына күчә телебезгә,*
*Бөек телебезгә.*
*Ят та түгел кебек инде*
*Бу тел безгә,*
*Балык булып барабыз бит*
*Үзебез дә.*

**Таныш бул!**

# «Кем иртә тора – шул барысына да җитешә»!

Әңгәмәдәш – **Раил САДРЕТДИНОВ**, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Өлгер, уңган, максат-хыялларын ак җилкән итеп, җилләргә бирешмичә алга бара. Сүзем татар журналистикасы бүлегенең 2 нче курсында гына укучы Гүзәлия Гыйниятуллина турында. Аны кайда гына очратмыйсың! Бер карасаң, университет эскәмиясендә, икенче карасаң, телевидениедә яки берәр мөһим эш белән чыгып киткән, өченче карасаң, татар яшьләре арасында... Барысына да ничек өлгерә диген ә?!.



**– Гүзәлия, туган ягың – Башкортстан төбәге. Ә ул яклар талантларга бай, татар мәдәниятенә, сәнгатенә күп шәхесләр биргән төбәк.**

– Чыннан да, Башкортстанда туган татарлар – бик талантлы халык. Мин чын татар гаиләсендә тәрбияләндем. Әнием белән әтием энем Алмаз белән мине туган телегезне онытмагыз, белегез дип үстерделәр. Ә нигезне әбием Флүрә салды. Ул мине 3 яшьтә үк сәхнәгә чыгарып, шигырьләр сөйләтте. Шулай мин сәнгать, мәдәният, әдәбият дөньясына кереп киттем.

**– Ә журналистика белән «җенләнү» кайчан башланды?**

– Безнең гаилә – табиблар һәм урманчылар гаиләсе. Әлбәттә, барысы да мине табиб итеп күрде... Шулай да 9нчы сыйныфка җиткәч, карашларым үзгәрде. Мин укыган Әнгам Атнабаев мәктәбендә, газета чыгарабыз, дип игълан иттеләр. Һәр сыйныфтан бер язма кирәк иде. Безнең сыйныфтан мин яздым, шулай мин үземне журналист буларак сынап карадым. Аннары район газетасына, республика, хәтта Татарстанның газета-журналларына да яза башладым.

**– Бу өлкә нәрсәсе белән кызыксындырды? Өметләр акландымы?**

– Журналистикада мине төрле кешеләр белән аралашу кызыксындыра. Мин бит көн саен өр-яңа хәбәрләр ишетәчәкмен, кеше язмышында ниндидер роль уйнаячакмын, чөнки алар, миңа ышанып, үзләренең тормыштагы хәлләрен сөйлиләр. Журналист, минемчә, иң кызыклы профессия. Кешеләр өчен файдалы эш башкару, кирәк икәнеңне аңлау! Димәк, мин юкка гына яшәмим! Әле 2нче курста гына укыйм, шуңа күрә өметләр турында төгәл әйтә алмыйм. Чынында, үз мәгълүмати үзәгемне тудырасым килә. Нәрсә белән бәйле булуы турында әле әйтә алмыйм, ләкин шундыйрак дулкында барырга тырышачакмын.

**– Журналистикадан кала, башка өлкәләрдә дә актив бит син.**

Бөтендөнья татар яшьләре оешмасы белән татар теленә, татар яшьләренә, гомумән, татар халкына кагылышлы төрле чаралар үткәреп йөрибез. Гомумән, төп максатым – бар татар яшьләрен берләштерү, алар өчен уңайлы шартлар тудыру.

**– Ничек барысына да вакыт җиткереп була?**

– Мин һәр көнне продуктив үткәрергә, бер мөмкинлекне дә кулдан ычкындырмаска тырышам, чөнки яңадан андый бәхет елмаймый. Көн тәмамланганда, нәтиҗәләр ясарга яратам. Һәм, әлбәттә, көн саен үз өстемдә эшләргә тырышам, үземне ничек булса да алга этәрәм. Әтиәнием горурлансын, дип тырышам. Дуслар, сезгә бер сер ачам: «Кем иртүк тора – шул барысына җитешә»!

**– Яраткан хоббиең?**

– Мин төрле чаралар үткәрергә яратам. Татар халкының милли биюләре, аш-суы, гореф-гадәтләре кызыксындыра. Шуңа кагылышлы әйберләр җыям. Шигырьләр дә язгалыйм, күңел серләрем шуларда чагыла.

**– Беләм, китаплар укырга яратасың. Соңгы укыган китабың?**

– Зифа Кадыйрованың «Көтеп узган гомер» әсәре. Зифа апаның барлык китапларын укып бетердем диярлек. Аның әсәрләрен укыгач, чыннан да, саф, татлы мәхәббәт бар икәненә инанасың. Рәхмәт Зифа апага! Мин аңа сокланам! Нинди генә авырлыклар белән очрашкан булса да, башын югары күтәреп, алга атлый. Афәрин!

**– Тормышта төрле чаклар була. Янда һәр эшеңне бәяләүче, хуплаучылар булу кирәк.**

– Иң кадерле кешеләрем ул – гаиләм. Кадерле әтием, татлы телле әнием, шук, ләкин көчле энем һәм миңа юл күрсәтүче дәү әнием. Алар – минем тормыш байлыкларым, күз нурларым. Бар эшләгән эшләрем дә алар өчен, аларның елмаюларын күрү өчен.

**– Ә кумирларың бармы?**

– Әлбәттә! Яраткан шагыйрем – Әнгам Касим улы Атнабаев. Балачактан аның шигырьләрен укып үстем. Хәзер дә яратып укыйм. Шигырьләре тормышчан, йөрәккә кадерле һәм сокландыргыч. Кызганыч, хәзер андый шагыйрьләр юк.

**– Бүген нинди уй-хыяллар белән янып яшисең?**

– Һәр кешенең дә үз максат-хыяллары бар, мин дә искәрмә түгел. Ләкин бар серләрне дә ачып бетерәсем килми. Элек әбибабайларыбыз әйткәнчә: «Хыялларыгызны сөйләмәгез, чынга ашмый». Шуңа, бу сүзләргә таянып, әйтмим әле.

**Хыял чынга ашсын өчен, көчле теләктән кала, ихтыяр көче дә кирәк. Иң мөһиме, тырышлык! Бу сыйфатларга син 100% ия. Димәк, соңгы арада бер хыялың тормышка ашмагае!..**

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.